| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

с. Шланга

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 январь 2016 ел № 5/3

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Шланга авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, "Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" 2014 елның 14 гыйнварындагы 3 номерлы, 2015 елның 12 февралендәге 85 номерлы үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү буенча уртак инициативаны түбәндәге эш буенча тәкъдим итәргә:

"2016 елда Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Шланга авылының Тукай урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

- Шланга авылының К. Маркс урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

- Шланга авылының Комсомол урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

- Шланга авылының Фрунзе урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

- Шланга авылының Киров урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау- 33 000 сум акча тотылган

**«ӘЙЕ»** **«ЮК**.».

2. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы

Шланга авыл җирлеге башлыгы: А. А. Мөхәррәмов